СОВЕТ НИЖНЕУСЛОНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ТҮБӘН ОСЛАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ — КАРАР

15.11.2021 — 27-147

с. Нижний Услон

Торак пункт территориясенең әлеге өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрү өчен Түбән Ослан авыл җирлеге составына керүче торак пункт территориясенең бер өлеше чикләрен билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Түбән Ослан авыл җирлеге Уставының 24 ст. нигезендә

Югары Ослан муниципаль районы
Түбән Ослан авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Гражданнарның яшәвенең түбәндәге территорияләре чикләрендә торак пункт территориясенең әлеге өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын уздыру өчен территориянең бер өлеше чикләрен билгеләргә:

Түбән Ослан авылы:
Ленин урамында 3 нче номерлы торак йортлартан 79нчы йортка кадәр йортлар
Чернышевский урамында 7нче йорттан 9нчы йортка кадәр торак йортлар
Спортивная урамында 5 йорттан 28 нче номерлы йортка кадәр торак йортлары;

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет - финанс һәм икътисадый мәсьәләләр буенча Түбән Ослан авыл җирлеге Советының даими комиссиясенә йөкләргә.

3. Әлеге карарны Югары Осланмуниципаль районы рәсми сайтында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында, Түбән Ослан авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Совет рәисе,
Түбән Ослан авыл җирлеге башлыгы — А.В. Архиреев